**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Салтык авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

28 нче ноябрь 2022 ел № 6

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 нче елның 28 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Салтык торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:
- Олы Салтык авылында урам юлларын ремонтлау (вак таш җәелгән чокыр ремонты, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);
- Олы Салтык авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 236 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 118 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 118 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге составына керүче Олы Салтык авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Салтык торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны

җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

- Олы Салтык авылында урам юлларын ремонтлау (вак таш җәелгән чокыр ремонты, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);
- Олы Салтык авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)" карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 10(ун) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы КамаТамагы
муниципаль районы Олы Салтык
авыл җирлеге башлыгы: Р.М. Вафин